СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** | **КАРАР**

30.09.2021 г.Лениногорск № 61

«Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм туктату тәртибен раслау турында» 2011 елның 9 декабрендәге 130 номерлы (2012 елның 2 июнендәге үзгәрешләр белән) карары белән расланган Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм туктату тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Җирләрне мелиорацияләү турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына агролесомелиорация үткәрүне хокукый җайга салуны камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 27 декабрендәге 477-ФЗ номерлы Федераль законга (1-4 статьялар) таянып, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Лениногорск район Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм туктату тәртибен раслау турында» 2011 елның 9 декабрендәге 130 номерлы (2012 елның 2 июнендәге үзгәрешләр белән) карары белән расланган Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм туктату тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 бүлекнең 3 пунктының 4 подпуктында «дренаж» сүзләреннән соң «һәм сугару системалары» сүзләрен белән тулыландырырга;

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninoqorsk.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны экология һәм табигатьтән файдалану буенча даими комиссиягә һәм Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Лениногорск муниципаль районы
Башлыгы, Совет рәисе Р.Г.Хөсәенов